ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ

Б О Е Р Ы К

20.07.2017 **Казан ш.** № 474

«Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында»

2004 елның 27 июлендә кабул ителгән 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында» Федераль законның 17 маддәсенең 1 өлешендәге 3 пункт нигезендә

**боерам**:

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. 2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үземдә калдырам.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт
министрлыгының 2017
елның 20 июлендә кул
куелган 474 номерлы
боерыгы тарафыннан
расланган

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле
тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында
коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки
идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү
тәртибе

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе (алга таба – Тәртип) 2004 елның 27 июлендә кабул ителгән «Россия Федерациясе гражданлык хезмәте турында» 79-ФЗ номерлы федераль законның 17 маддәсенең 3 өлешендәге 3 пункт нигезендә эшләп чыгарылган.

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәлек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез милек хуҗалары ширкәте (алга таба – коммерциячел булмаган оешма) белән идарә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү процедурасын көйли.

Әлеге Тәртип эшкә алучысы булып Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры торган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында эшләүче Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә кагыла.

2. Түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмаларның идарәсендә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү турында гариза (алга таба – Гариза) гражданлык хезмәткәре тарафыннан язма рәвештә әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасына карап тутырыла.

3. Гражданлык хезмәткәре Гаризаны коррупцион һәм башка төр хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы булган затка (алга таба – Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җаваплы зат Гаризаны килгән көнне үк әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча Журналда терки.

5. Җаваплы зат Гаризаны беренчел карауны тормышка ашыра һәм нәтиҗә буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны беренчел карау барышында Җаваплы зат Гариза тапшырган гражданлык хезмәткәреннән күздә тотылган коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуның функцияләрен билгели торган язмача аңлатмалар һәм документлар сорарга хокуклы.

Бәяләмә үз эченә гражданлык хезмәткәренә түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмаларның идарәсендә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү яки баш тарту турында җөмләне алырга тиеш.

6. Гаризаны теркәгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча Җаваплы зат Гариза һәм Бәяләмәне, шулай ук башка материлларны (булган очракта) карау һәм дәүләт гражданлык хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмаларның идарәсендә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү яки баш тарту турында карар кабул итү өчен

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министрына (аның вазыйфаларын башкаручы затка) бирә.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Гаризаны алган көннән башлап ике эш көне дәвамында карар кабул итә.

7. Җаваплы зат Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан карар кабул ителгән көннән башлап ике эш көне дәвамында гражданлык хезмәткәренә Гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм кул куйдыртып Гаризаның дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча сектор мөһере белән расланган министр резолюциясе белән булган күчермәсен тапшыра. Гаризаның Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры резолюциясе булган төп нөсхәсе гражданлык хезмәткәренең шәхси эшенә теркәп куела.

---

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре
һәм спорт министрлыгында Татарстан
Республикасы дәүләт гражданлык
хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле
тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер
башкарма орган сыйфатында коммерциячел
булмаган оешмаларның идарәсендә
катнашырга яки идарәләренең коллегиаль
органнары составына керергә рөхсәт итү
тәртибенә
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре
һәм спорт министры
В.А.Леоновка
______________________________________
______________________________________
(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфа һәм структур бүлекчә,
______________________________________
тору урыны,
______________________________________
телефон номеры)

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмаларның идарәсендә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү турында

гариза

Миңа түләүсез нигездә __________________________________________________________
(бердәнбер башкарма орган яки идарәнең коллегиаль органы атамасы)
________________________________________________________________________.сыйфатында
(иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәлек,
______________________________________________________________(кирәгенең астына сызарга)
дача кулланучылар кооперативы, күчемсез милек хуҗалары ширкәте)
идарәсендә катнашырга, идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итүегезне сорыйм.

| ________________ | __________________ | ________________________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (фамилия, инициаллары) |

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмаларның идарәсендә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибенә
2нче кушымта

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмаларның идарәсендә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү турында гаризаларны теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № | Дата | Ф.И.А.и., гариза бирүченең вазыйфасы | Гариза бирүченең имзасы | Регистраторның Ф.ИА.и. | Регистраторның имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |